Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Рус Акташыҗирлегенең
Акташ Станция сеторак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре
турындагы КАРАРЫ

27 ноября 2020 ел №7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының35 статьясы, 2020 елның 26 ноябрендә 18 сәгать00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге:

«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлегенең Акташ Станциясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Акташ Станциясе юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?” соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 73 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 44 кеше, бу 60% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 35«РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 9«КАРШЫ»позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташыҗирлегенең Акташ Станцисе торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы җирлегенең Акташ Станцисе авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2021 елда 500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрнебашкаруга юнәлдерергә: Акташ Станциясе юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түлә.

4.Әлеге карарны«Альметьевский вестник» газетасында бастырырга,Акташ Станциясе, контора бинасытерриториясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматларрәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты«Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрынакертүөченҗи бәрергә.

Гражданнар җыенында рәислекитүче С.А. Белоногов